КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 май г.Казань № 658

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2024 ел, 11 октябрь, 877 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2024 ел, 11 октябрь, 877 нче карарына, аңа түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^{1}$. «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм» федераль проектының яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чарасында Татарстан Республикасы территориясендә күрсәтелгән чарада катнашу турында гариза биргән көнгә кимендә 5 ел даими яшәүче яшь гаиләләр катнашырга мөмкин, дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин